**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» июль, 2021 ел № 419

2021 елның 2 яртыеллыгына салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31 номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» Коммерцияле булмаган партнерлыгының 2021 елның 12 февралендәге 48 номерлы хаты белән Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы ставкасы:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 439 724 сум

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 1 832 376 сум

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 2 355 912 сум

1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 3 141 216 сум

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 3 926 520 сум

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 4 711 824 сум

1.1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 5 497 128 сум

Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык керем күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 15 847 сум

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 10 083 сум

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 8 643 сум

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдалануны социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондын исәпкә кую һәм аларга торак урыннары бирү максатларында аз керемле дип тану өчен файдаланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин